**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**02.02.2022ел** **№ 50**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 18 нче декабрендә 122 номерлы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Зәй муниципальрайонының Югары Шепкә авыл җирлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авылҗирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның18нче декабрендәге 122 номерлыЗәймуниципальрайонының Югары Шепкә авылҗирлеге Советы карарына түбәндәгеүзгәрешләрне кертергә.

1.1. 6 пунктның 29 абзацында «, 50 кв. м дан артык мәйданда һәм 30 куб.м дан артыграк күләмдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40. Индивидуаль торак йортлар милекчеләре (яки) яллаучылар (алга таба – торак йортлар хуҗалары) әгәр закон яки килешү белән башкасы каралмаган булса, бурычлы:

1) торак йортларның фасадларының, коймаларның (киртәләрнең),шулай ук йорт биләмәләре чикләрендә башка корылмаларның тиешле торышын тәэмин итәргә,аларны үз вакытында ремонтлау һәм буяуны башкарырга;

2) торак йортка номер билгесе тиешенчә урнаштырырга һәм аны төзек хәлдә тотарга;

3) йорт биләмәсе территориясен тәртиптә тотуны һәм тиешле санитар халәттә тотуны тәэмин итү;

4) газүткәргечләрнең, кабельле һәм һава электр үткәргечләренең һәм башка инженерлык челтәрләренең сак зонасында агачлар утыртырга рөхсәт итмәскә;

5) якын-тирәдәге территориядән чистартылган карны транспорт юлына, аларда инженерлык коммуникацияләренә һәм корылмаларга керүгә, җәяүлеләрнең үтеп йөрүенә комачауламаслык итеп һәм яшел утыртмаларның саклануын тәэмин итәрлек итеп өяргә;

6) үзәкләштерелгән канализация булмаганда бирелгән жир кишәрлеге чикләрендә санитар нормалар нигезендә жирле канализация, юынтык сулар чокыры, бәдрәф ясарга, аларны даими рәвештә чистартып һәм дезинфекцияләп торарга;

7) каты коммуналь калдыкларны пакетларгаяисә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарында (мәйданчыкларында)региональ оператор тарафыннан бирелгән башка савытларга салырга.»;

1.3. 83 пунктның икенче абзацында «23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр - эш көннәрендә, ә ял көннәрендә һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә - 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр,» сүзләре белән алмаштырырга;

1.4. 125 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«125.Шәхси торак төзелеше территориясендә рөхсәт ителми:

1) йорт биләмәләре чикләреннән читтә койма кую;

2)йорт биләмәләре чикләрендә һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә яфраклар, теләсә нинди калдыклар һәм чүп-чар яндыру;

3)йорт яны территориясеннән читтә гирес, күмер, тара, утын, эре габаритлы калдыклар, төзелеш материаллары өеп кую;

4)“Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирләрендә йорт биләмәсе территориясеннән читтә транспорт чараларын юарга;

5)вәкаләтле органнар белән килештермичә, йорт биләмәсе территориясе артында корылмалары төзергә, чүп-чар чокырлары ясарга;

6)әлеге территориянең урамнарында махсус транспорттан һәм урып-җыю техникасыннан файдалану мөмкинлеген кыенлаштыра торган яисә аларга комачаулаучы торган капламалар урнаштырырга;

7)территорияне төзекләндерү элементларын җимерергә һәм бозарга, сулыкларны пычратырга;

8)“Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге җирләрендә йорт биләмәсе территориясеннән читтә сүтелгән (төзек булмаган) транспорт чарасын куярга һәм сакларга;

9) якын-тирәдәге территорияне теләсә нинди калдыклар белән чүпләргә;

10)чүплек, кар, боз өемнәре ясарга.»;

1.5.124 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-кагы коммуналь калдыклар өчен контейнерлар урнаштыруны;»;

1.6. 174 пунктта «7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «эш көннәрендә 6.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр, ә ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә 9.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе _______________ Л.М.Камалиева